**ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**7 декабрь 2021 ел** **№2**

2022 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сарлы торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сарлы авыл җирлеге Сарлы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Сарлы авыл җирлеге Сарлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә, 2 Төркем инвалидларыннан 150 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- янгын сүндерү автомобиле йөртүче хезмәтенә түләү, янгын сүндерү автомобиле өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу;
- территорияне механикалаштырылган чабу буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;
- кышкы чорда юлларны чистарту буенча хезмәтләр өчен түләү;
- бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Инвалидлар декадасы», «Яңа ел»);
- МТЗ-82 өчен отвал сатып алу,
- чаралар үткәрү өчен аппаратура һәм җиһазлар сатып алу.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сарлы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Сарлы авыл җирлеге башлыгы

САРЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ / САРЛИНСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

М.Р.Шәрипов